| | |
|---|---|
| **СОВЕТ БИКБУЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗƏЛƏ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИКБАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

КАРАР

№2 05 ноябрь 2019 ел

Татарстан Республикасының
Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең
муниципаль хосусыйлыгында булган
милек объектлары турында мәгълүматны бастыру
Тәртибен раслау турында

06.10.2003 елдагы "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы №131-ФЗ Федераль законы нигезендә, муниципаль хосусыйлыкта булган объектлар турында мәгълүматны "Интернет" мәгълүмати-коммуникацияле челтәрдә урнаштыру һәм актуальләштерү өлешендә 2018 елның 5 апрелендә Россия Федерациясе Дәүләт Советында узган утырыш нәтиҗәләре буенча (2018 елның 15 маендагы (№ Пр-817ГС) Россия Федерациясе Президенты йөкләмәләре исемлеген гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Кушымта №1 нигезендә, Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгында булган милек объектлары турында мәгълүматны бастыру Тәртибен расларга.
2. Гамәлдәге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.
3. Гамәлдәге карар Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы "Бикбау авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең http:// bikbulovskoe.tatarstan.ru рәсми сайтында басылырга тиеш.

ТР Минзәлә муниципаль район
Бикбау авыл җирлеге Советы Рәисе: Л.Н.Мардамшина

Минзәлә муниципаль районы
Бикбау авыл җирлеге
Советы карарына
Кушымта № 1
№ 2 дата 05.11.2019ел

Татарстан Республикасының

Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгында булган

милек объектлары турында мәгълүматны бастыру

Тәртибе

1. Гамәлдәге Тәртип Минзәлә муниципаль районының Бикбау авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгында булган милек объектлары турында мәгълүматны аны алуда кызыксынган билгеле бер даирә затларны аңа керү белән тәэмин итү максталарында, Интернет мәгълүмати-коммуникацияле челтәрендә (алга таба – Интернет челтәре) бастыру процедурасын билгели.

2. Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлеге сайты (http:// bikbulovskoe.tatarstan.ru.) Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгында булган милек объектлары турында мәгълүматны Интернет челтәрендә бастыру өчен Минзәлә муниципаль район сайты булып тора.

3. Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлеге башкарма комитеты Бикбау авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгында булган милек объектлары турында мәгълүматны Интернет челтәрендә бастыруга вәкаләтле булып тора.

4. Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгында булган милек объектлары турында мәгълүмат бастырып чыгарылырга тиеш. Россия Федерациясе законнары нигезендә керү чикләнгән мәгълүмат бастырып чыгарылырга тиеш түгел.

5. Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгында булган милек объектлары турында мәгълүмат гамәлдәге Тәртипнең кушымта №1 нигезендә объектлар исемлеге рәвешендә бастырып чыгарыла.

6. Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгында булган милек объектларының бастырып чыгарылган исемлеге “online режимында күчемсез милек объектлары буенча белешмәле мәгълүмат” һәм “Ачык кадастр палатасы” Интернет челтәрендә Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография Федераль хезмәтенең рәсми сайтында мәгълүмати сервислар ярдәмендә күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан күчемсез милек объектлары турында актуаль мәгълүматларны кызыксынган затларның алу мөмкинлеге турында белешмәле мәгълүмат белән тулыландырыла.

7. Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгында булган милек объектлары турында мәгълүматны бастыру Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлеге башкарма комитетында исәпләнә торган мәгълүматлар нигезендә, Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгы реестрында башкарыла.
8. Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгында булган милек объектлары турында бастырылган мәгълүматны актуальләштерүне ярты елга бер тапкыр Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлеге башкарма комитеты башкара.

Татарстан Республикасы

Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең

муниципаль хосусыйлыгында булган

милек объектлары турында

мәгълүматны бастыру Тәртибенә

Кушымта 1

Татарстан Республикасы

Минзәлә муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең

муниципаль хосусыйлыгында булган милек объектлары турында

мәгълүмат

| № | Милек атамасы | Урнашкан урыны (адрес) | Мәйданы кв.м. | Максатчан билгеләнеше | Вакытлыча чик куюлар | Чикләүләр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |